Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

ЧАЯН



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ ОКТЯБРЬ * 2022 * КАЗАН

10





Анастасия ВАСИЛЬЕВА

Алмаз ХӘМЗИН

ИСӘН ЧАКТА ТАКТАШ, "ҮЛДЕМ", ДИГӘН...

Яши торгач, тулды җитмеш бишем,
Кояш чыга һаман бер яктан.
Күк болытсыз чакта күрәдер дә
һәм әйтәдер миңа: "Картайган".

Ә син, Кояш, атып-баеп йөреп,
Белмисең дә безнең халәтне...
Син – мәңгелек, ә мин – мизгел,
Яши башлыйм... йомам бәбәкне.

Кеше гомере кыска икән лә,
Уй-хыяллар кала шул килеш.
Сиңа, Кояш, Ходай бер юл биргән:
Калку-бату – артка юк йөреш.

Йолдызлар да күктә үзгәртмиләр
Йөрешләрен, танып беләбез.
Казык йолдыз гына бер кузгалмый
Тора, балкый. Ә без сүнәбез...

Тылкышмыйча дөнья халәтенә,
Бар җисемнәр яши үзенчә.
Тик кешеләр генә тынышалмый,
Милек өчен бугаз чәйнәшә.

Әхлак дигән гади төшенчәләр
Чыгып кача җанны чәрдәкләп.
Намус, вөҗдан ярсып, үксеп елый,
Шайтан көлә, ботын чәбәкләп.

Яшәмәдек, эшләмәдек диеп
Әйтеп булмый, без бик тырыштык.
Без тудырган, без туплаган малны
Карап торып читкә шудырдык.

Шпаналар үрчеткәнбез икән,
Баш күтәрми эшләп, белмичә...
Күрәсезме, алар – өске катлам,
Ә без хәзер – хәерче, куштан...

Мин һаман да язам, ярсый-ярсый,
Гаделлекне яклап илемдә.
Хак көрәшем минем акланырмы
Исән йөргән соңгы көнемдә?

Оялыпмы безнең яшәештән
Кояш батса, иртән чыгармы?
Таң кашына кунса кара төтен,
Җан чыдамый чаңын сугармы?..

Бер игелек эшләп булмый монда,
Әйбәт булып калу икеле...
Исән чактук Такташ, "үлдем", дигән,
Мин дә, ахры, шуның шикелле.

Александр АЛЁШИН





ШОМБАЙ болай диде...

Хөрмәтле Чаян! Минем күзәтүемчә, хәзерге хатыннар, заманадан артта калмас өчен, косметика белән кирәгеннән артык мавыгалар шикелле. Мондый «чибәркәйләр»не күргәч, кайчагында елап җибәрәсе килә...

Л. ТӘХИЕВ

КАЗАН

– **Алар ботканы май белән, ә йөзне косметика белән бозып булмый, дигән гыйбарә буенча эш итәләр бугай,** – диде Шомбай ага, укучыбызның хатын укып чыккач.

Ринат АБЗАЛОВ

АВАЗЛАР

Ярып керә җанны табигатьнең
Ходай биргән барча тавышы:
Кышның салкын тынычлыгын бозып,
Ватылышып бозлар агышы,
Җирне азаплаган челләдән соң
Күкне ярган яшен камчысы,
Кара болытларның, усалланып,
Йөзгә бәргән салкын тамчысы.
Елга буендагы тал астында
Уфылдавы шомлы чоңгылның,
Тәрәзәне шакып кара төндә,
Шыбырдавы көзге яңгырның.
Ябалдашлар белән бәрелешеп,
Агачларның ярсып шаулавы,
Урман эчләрендә әллә буран,
Әллә явыз бүре улавы...

Шомлы аваз, ярсып шаулаумы ул –
Йөрәгемә керәдер тулып.
Тик барыбер нечкә күңелемдә
Яңгырый алар моңлы җыр булып...

Михаил ЛАРИЧЕВ





Александр ШУЛЬПИНОВ

Белем алырга сәяхәт

«Уку яктылык, ә надан-лык – таңнан эшкә", – дип шаярталар кайбер үткен телләр. Тик Казанның яңа торак комплекслары һәм коттедж бистәләрендә яшәүчеләр бу сүзләрдән елмаймаслар иде, мөгаен. Киресенчә, авыр сулап куярлар иде – аларның балаларына бит иртә таңнан тәпи-тәпи мәктәп сукмагыннан атларга туры килә...

Демографик кризис турындагы фаразларга карамастан, илдә беренче сыйныфка баручы балаларның саны елдан-ел арта бара. Менә республика буенча да соңгы вакытта бу өлкәдә зур күтәрелеш күзәтелә. Бу яхшы күренеш, әлбәттә, ләкин мәктәпләр җитми шул! Казанда, мәсәлән, 30 уку йорты җитми. Бу җитешсезлекнең сәбәбе башка күтәрелештә – төзелешнең алга китүендә. Яңа торак комплекслар, яңгырдан соң гөбә кебек, арт-каннан-арта тора. Ә анда, кырмыска оясыдай төзелгән кеше өннәреннән башка, кагыйдә буларак, бернинди балалар бакчалары, поликлиникалар һәм шул ук мәктәпләр юк. Менә шундый икеләтә күтәрелеш килеп чыга.

Узган елның кышында мәктәпләренә берничә чакрым үз җайлары белән барырга мәҗбүр Привольный һәм Вишнёвка бистәләрендә яшәүче балалар флэшмоб оештырганнар иде. Алар, өлкән абзыйларга мәктәпнең ераклыгы турында искә төшерү йөзеннән, үз гәүдәләреннән кар өстендә "мәктәп" сүзе җыйганнар иде. Балаларга ул чакта, мәктәп булыр, ләкин соңрак, дип вәгъдә иттеләр; ә ата-аналарына исә янап куйдылар: мондый җитди эшләрдә ныгып җитмәгән балаларны файдалану ярамый, янәсе.

Яңа уку елы башланды. Һәм яңадан бистә укучылары, дәресләргә соңга калмас өчен, иртәнге биштә торып, начар юл буенча җәяүләп автобус тукталышына юл тота. Ә вәгъдә ителгән мәктәп ничек? Кузгалыш бар шикелле – бина өчен урын билгеләнгән һәм казыклар кагып куелган.

Торак комплексның янәшәсендә мәктәп булса да, ул шыплап тулы. Мәсәлән, "Салават Күпере" һәм "Весна" комплексларындагы лицейлар унбишәр беренче сыйныф җыйган. Үзенә күрә рекорд та бар – сыйныфларны билгеләү "С" хәрефенә барып җиткән! Ә 1200 укучыга исәпләнгән "Солнечный город"тагы мәктәп ике тапкыр күбрәк укучы кабул итәргә мәҗбүр. Йөзләп баланы ераграк урнашкан мәктәпләргә күчерергә туры килгән – алар бинага сыймаган. Ата-аналары алдында кыз-улларын белем алу урынына урнаштыру мәсьәләсе килеп туа.

Мәктәп төзү – арзан нәрсә түгел. Бер уку йорты төзү өчен 1,5 миллион сум һәм бер өем документлар кирәк. Балалар да бюрократия эшләре хәл ителүгә караганда, тизрәк үсә. Шуңа күрә бу мәсьәлә мәктәп тигезләмәсен чишүгә караганда, катлаулырак булып чыга. Ләкин хәл бөтенләй үк күңелсез түгел. Вишнёвкада яшәүче өлкән сыйныф укучысы Марат бу хакта менә нәрсә диде:

– Аның каравы, үземнең булачак балаларыма сөйләр әйбер булыр. Яңгырга һәм карга карамастан, көн саен белем алу өчен сәяхәткә чыгуым турында... Ичмасам, аларны мондый мажаралы юллар көтмәс дип ышанасы килә...

Людмила САФИУЛЛИНА



Валерий ТАРАСЕНКО











• • •

– Ни өчен сез урмандагы тыюлыкта калыккан иң яхшы торак комплексын төзүгә каршы чыкмадыгыз?!

– Миңа каршы килә алмастай чемодан китерделәр...

• • •

Бер кирпечтән тулы бер йорт төзеп буламы? Була икән, берне генә түгел, берничәне! Һөнәренең серләре белән ЮХИДИ инспекторы Галиуллин бүлеште.

• • •

– Ни өчен социаль челтәрләрдә аралашмыйсың?

– Мин – психиатр. Эшемдә дә андый аралашулар җитәрлек.

• • •

Элеккеге фильмнар уйларга мәҗбүр итәләр иде, хәзергеләре алай түгел. Хәзергеләрен карыйм да уйланам: нигә соң әле мин моны карадым, дим?!

• • •

Берзаман бер акыллы кеше сөйләшми башлады. Дөньялар тынычсызланды, ә сердәшләр ышанычсызланды.

• • •

Уйладым-уйладым да, әшәке гыйфрит белән сугышка чыгарга булдым – яшел елан белән, ләкин сугышта үзең генә батыр кала алмаска мөмкин. Ашыгыч рәвештә тагын ике батырны табарга туры килде.

• • •

– Әйтегез әле, Ребе, минем Сараның туйга хәтле баласы туды, бу зур гөнаһмы?

– Нишләп гөнаһ булсын! Бала туйның кайчан буласын каян белсен?

• • •

ЮХИДИ посты өстеннән сәгатенә 2000 километр тизлектә НЛО очып үтә. Гаишниклар шаккатып карап калалар дип уйлыйсызмы? Юк, Галәм кунаклары шок хәленә төшә, ник дисәгез, икенче көнне үк аларның Альфа Центавра галактикасына штраф турында квитанция килеп җитә!



АГАЙ-ЭНЕ АК МЫЕК...

Республикага килгән Себер-Урал нефть-газ компаниясе туган-тумачалык белән көрәшергә булган. Түбән Камада һәм Казанда үткәрелгән тикшерүләр якын туганнарның бер-берсенә карата турыдан-туры буйсынуда торганнарын күрсәткән. Әйтергә кирәк, элекке җитәкчелек монда бернинди начар нәрсә күрмәгән, хәтта бу хәлне үрнәккә куйган: акционерларның балалары җитәкче булып эшлиләр. СИБУР исә моңа башкачарак карый. Алар хезмәт династияләрен ихтирам итәләр, ләкин ул династияләрнең җитәкчелеккә кагылышы булмаска тиеш. Беренче эш итеп "агай-энеләргә" шәхси элемтәләрне юкка чыгарырга һәм хезмәткәрләрнең киләчәк язмышын хәл итәргә тәкъдим ителгән.

ЯЛГАН СӘЯХӘТ


Җәй ахырында ике дистә чамасы турист мошенниклар тырнагына эләккән. Болай да зур катлаулыклар белән бәйле чит илгә чыгуны Казандагы туристик фирмаларның берсе тагын да катлауландырып җибәргән. Яз көне үк сатып алынган путёвкаларның ялган булганлыклары турында туристлар очып китәр алдыннан гына белгәннәр. Сәяхәтчеләрнең үзләре әйтүенчә, алар юлламаларны гадәттән тыш арзан булуына кызыгып алганнар.

САТЛЫК ГЕРМАФРОДИТЛАР

Чаллы эшмәкәрләре Казакъстан фермерларын бик җитди итеп өткәннәр. Фермерлар, сөйләшенгәнчә, шәп нәселле Чехия сыерлары урынына нәселсез һәм авыру эре мөгезле терлек алганнар. Кайберләре исә, гомумән, үрчүдән мәхрүм гермафродит булып чыккан. Ялганчы сәүдәгәрләрне хәзер суд көтә.

КУЛЬТУРАСЫЗ МӘДӘНИЯТ

Чаллыдагы "Мастеровые" Рус драма театрының яңа бинасында гадәти булмаган скульптура күрергә була. Мәдәният учагының бәдрәфендә, унитазга утырып, телефоннан сөйләшүче кыз урнашкан. Бу сәнгать әсәрен тудыру белән җитәкчелек иткән хезмәткәр хөрмәтенә кызыйга Таня дип исем биргәннәр. Шәһәр халкы бу сынны төрлечә кабул иткән: кемдер Брюссельдәге "пес итүче малай"ны исенә төшергән – бездә шундый кыз булсын, янәсе, ә икенчеләре, мондый скульптураларга мәдәният учреждениесендә урын булмаска тиеш, дип каршы чыккан.





ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР

Буйдак патша кебек яши һәм эт кебек үлә; өйләнгән ир эт кебек яши, патша кебек үлә.

Әгәр хатыннар бер кеше өчен генә бизәнсәләр, бу озак дәвам итмәс иде.

Ир-ат кеше үзенә кадәр булганнардан көнләшә, ә хатын-кыз — үзеннән соң булачаклардан.

Мәхәббәттә бәхетле булыр өчен сукыр булу кирәкми, вакыты-вакыты белән күзеңне йомып тору да җитә.

Хатын-кызны бәхетле итәр өчен аңа берничә кәнфит һәм күзгә бирү җитә.

Уксус шәрабтан барлыкка килгән кебек, никах та мәхәббәттән барлыкка килә.

(Хатын-кыз белгечләре мәҗлесендә язып алынды)





Рөстәм ЗАРИПОВ

КЕМНӘР АЛАР?

Алда үтәлмәслек томан – томаналык,
Ишкәкләре – батыйллык* һәм будалалык**,
Минбеләмлекләре киерелгән җилкән,
Фикерләре чыга арттан, саркый үттән,
Әдәбият сайлыгында алар күптән...
Мидәге сырларын инде вакыт сөрткән..
Саллары акмый, бүрәнәләре бүрткән...
Маңгай тар, җан түбән, авыз-борын күпкән...
Күрче, Сократ, Хәйям булып "уйланалар",
Милләт хадиме булып та кыйланалар,
Болганчыкта балык тотулары уңай...
Исем, бүләк сосу өчен шулай кулай...
Армый-талмый банкетларда сыйланалар,
Тел беткәндә китап санап юаналар,
Йә, әйтегез, тарих өчен кемнәр алар?
Милләт тәнендә үлекле чуан алар...

* Батыйль – бозык.
** Будала – ахмак, буталган.





Александр БРЮХАНОВ

Күңел ачу

Кич белән Нәҗия гадәттәгечә ашарга әзерли башлады. Кинәт телефон шалтырады.

– Алло, – диде, йомшак кызлар тавышы, – күңел ачарга теләмисезме...

– Ничек... күңел ачарга? – дип сорады, берни дә аңламыйча, Нәҗия.

– Сез бары тик "әйе" диегез, һәм без бөтен нәрсәгә әзер...

– Сез кайдан? – дип икенче соравын бирде Нәҗия.

– Каян булсын, идарәче компаниядән инде...

– Нәрсә баш катырасыз, сез кич белән эшләмисез ич. – Нәҗия трубканы ташлады... Аннан соң уйга калды... Телефонын алды, җитди кыяфәт белән, кирәкле номерны җыйды.

– Алло, бу Идарәче компаниядме?..

Трубкадан күңелгә ятышлы ягымлы хатын-кыз тавышы ишетелде. – Элемтәдә Идарәче компания. Без сезгә егетләребез һәм кызларыбыз белән күңел ачу тәкъдим итә алабыз...

Нәҗия, кая эләкқәнен һәм нәрсә тәкъдим иткәннәрен аңларга тырышып, тынып калды. Ә трубкадан шул ук тавыш агыла бирде:

– Кая килергә? Нинди костюмнарда кулай күрәсез – урам себерүченекенме, әллә сантехникныкынмы? Авария машинасы формасы белән дә була... Хезмәт күрсәтү түләүле...

Нәҗия трубкасын куйды. Нәрсә бу? Телефон станциясендә берәр нәрсә бутаганнардыр инде. Ул калтыранган куллары белән кирәкле номерны җыйды.

– Әлү, бу телефон станциясеме?

– Әйе, бу телефон станциясе, – дип җавап бирде чишмәдәй челтерәп торган саф тавыш. – Безнең телефонисткалар йә монтёрлар белән күңел ачарга теләмисезме? Адресыгызны әйтегез...

Нәҗия янә телефон трубкасын куйды:

– Нинди шакшылык – моны болай гына калдырырга ярамый.

Бер минуттан соң ул полиция номерын җыя башлады...

– Алё, полиция... Сезне дежур кыз Ляля тыңлый, – бу инде тәҗрибәле һәм күпне күргән хатын тавышы иде. – Тоткарланган гражданнар белән күңел ачарга теләмисезме? Богаулар һәм юл инспекторы таякчыгы белән өегезгә дә килә алабыз...

Нәҗия трубкасын ташлады... Һушыннан язып бару халеннән аны ишек чылтыравы чыгарды...

– Ишеккә дә килеп җиттеләр инде әллә?

Ул шкаф өстеннән уклау алды һәм ишекне ачып, киерелеп, аны караңгыга томырды...

– Ой-ёй-ёй!! – ишек артыннан таныш тавыш ишетелде, һәм ире керeп ауды...

– Ни өчен? – дип сорады ул мескен тавыш белән, күз астындагы зәңгәрләнеп килүче төмгәкне тотып...

– Синең хатыннарың өчен. Кич буе шалтыраталар, күңел ачарга тәкъдим итәләр, – диде бөеренә таянып Нәҗия...

–Син оныткансың, бүген гашыйклар көне бит, – дип исенә төшерде ире. – Бөтен оешмаларда да белгели торганнардыр...

– Ә мин, җүләр, шаярталар дип торам тагын, – дип, тирән сулап куйды Нәҗия. – Алайса чишен, ашап ал, ә аннан соң күңел ачарбыз, бәйрәм булгач... Сиңа нәрсә күбрәк ошый – чүмечме, әллә уклаумы?..



Виктор ФЁДОРОВ



Михаил ЛАРИЧЕВ



Вячеслав ШИЛОВ



Башкорт ядкаре



Башкортның милли юморын тулысынча "Һәнәк" юмористик журналы гәүдәләндерә дип әйтергә була. Ул йөз ел буе диярлек үзенең битләрендә аның иң гүзәл үрнәкләрен җыеп, сайлап, бастырып килгән. Утыз ел дәвамында журнал белән легендар шәхес Марсель Сәлимов җитәкчелек иткән. Ул – баш мөхәррир, язучы, драматург, күпсанлы премияләр лауреаты һәм мактаулы исемнәр иясе. Ә безнең өчен аның төп исеме – "Чаян"ның атказанган дусты! Бүген ул бездә кунакта!

Марсель СӘЛИМОВ

КЫСКА ИТӘКЛЕ ДЕМОКРАТИЯ

Яз җитте. Әбиләр туннарын салып ташлады, кызлар кендекләрен ачып йөри башлады. Күңелле!

Әле менә кыска итәкле кыз артыннан атлап барам. Шәәп! Кызык, алдан караганда да шулай шәпме икән? Мин аны узып китәргә итәм, ләкин куып җитә алмыйм. Без яшь чакта кызларның аяклары кыскарак була иде сыман... Озын аяклы кыз артыннан кызу-кызу атлыйм.

Ә минем арттан бер әби йөгерә. Таныш кебек тә үзе, кайчандыр кайдадыр күргәнем бар шикелле. Мине туктатып, хәбәр тапшырырга исәбе. Надоел инде бу әбиләр! Сөйли башласалар, сүзләре бетми. Юри ныграк чабам. Ул исемемне әйтеп кычкыра. Мин, ишетмәгән булып, тагын да тизрәк элдертәм.

Капыл артымда гөрселдәп багана аудымыни. Борылып карасам, кайчандыр университетта бергә укыган чибәркәй, хәзер бөтенләй әбигә әйләнгән Фирүзә тротуарда аягын күтәреп ята.

– Харап булды! – дип үрсәләнде ул.

Мин аңа ярдәмгә ашыктым:

– Аягың сынды мәллә?

– Аяк кына булса...

– Кабыргаң сындымыни?

Ул, ачуланып:

Кабырга түгел, каблугым сынды, – дип, итегенең үкчәсен күрсәтте.

– Аллага шөкер, – дидем, тынычланып, – кабыргаң исән икән.

– Кабырга сынса, ялганыр иде әле. Каблугым әрәм булды, – тип өзгәләнде Фирүзә. Еламый гына, бахыр.

Мин, аны җәлләп:

– Ашыкмаска кирәк иде, мондый тайгакта... – диган идем, ул кызып китте:

– Ашыкма, имеш! Үзең бит озын аяклы кыз артынан ашкынып чабасың. Куып җитәрлек тә түгел.

– Гафу ит, Фирүзәкәй, уйга бирелеп киткәнмен.

– Кызлар итәгенә карап, нәрсә уйлыйсың, картлач?

– Демократия турында баш ватам. Безнең демократия хатын-кыз итәге кебек бит. Йә аны бик нык тарайталар, йә чамасыз киңәйтәләр. Соңгы вакытта хакимият әһелләренең кырын эшләрен каплап торган япманы шактый күтәрделәр. Кыска итәкле кыз шикелле. Кем әйтмешли, кызлар итәкләрен кыскартмаса, аякларының кәкре икәнен белмәс тә идек.

– Кызык, әй, кимчелекләрне элек «Һәнәк»кә эләләр иде, хәзер – интернетка. Ниләр генә юк анда хәзер!

– Ачык сәясәтнең максаты шул бит, Фирүзәкәй: кәкрене дә, төзне дә яшермичә халыкка күрсәтү.

– Бер караганда, дөрес инде. Әле менә авылга кайтып килдем. Дустым сөйләп торды: безнең башлык туган-тумачасы белән бергәләп районыбыздагы бар мөлкәтне прихватизациялап бетерде, ди. Шул хакта анонимка язып, интернетка салам әле, ди.

– Салсын әйдә. Демократия булганда.

– Мин дә шулай дим шул. Демократия бит ул, үзең әйткәндәй, хатын-кыз итәге кебек. Әле мини, әле макси. Модасына карый...

– Нәкъ шулай! Фәкать мини белән макси арасында. Мода ничек кенә үзгәрмәсен, аны минидан югары күтәреп тә, максидан түбән төшереп тә булмый.

Шулчак кыска итәкле кызны шортик кигән егет кочаклап алды һәм күккә чөйде. Кызның итәге корсагына шуып менде дә аның ялтыравык балдак кидерелгән кендеген каплады...

– Нәрсә, күзеңне чекрәйтеп торасың, оятсыз?! – дип җикеренде миңа Фирүзә. – Демократия күргәнең юкмыни? – Ул, үкчәсе төшкән итеген кулына тотып: – Күтәр мине! – диде. – Оекчан йөртмәссең бит яшьлек дустыңны?! Хәтереңдәме, студент чакта син мине дискотекадан ятакка кадәр күтәреп кайткан иден?

Демократиясез үткән яшьлегемне сагынып искә төшерсәм дә, ул чактагыдан ике-өч тапкырга авыррак Фирүзә әбиегезне күтәрергә батырчылык итмәдем.



Юрий МӨХТӘРЕВ "Һәнәк"

Наталья БАХТИНА

БИСКВИТ

Әйе, ул көнне өстәмә тагын бер түтәл артык булгандыр. Ләкин кыш буе кәрәк сагынып яшәгән бөтен алты сутый хуҗалары кебек, Әсма да ире белән таңнан коймага кадәр билен турайтмады. Арып-талган, ләкин бәхетле Әсма ул түтәлнең артык булганын иртәгесен генә аңлады. Аркасы бишенче көн тораташтай катып калган хәлдә, хәтта кибеткә дә, исемлек тотып, ире берүзе генә йөри. Менә хәзер дә Әсма, күзлеген киеп, үскән бәяләргә уфтанып, алынган әйберләрне исемлек белән чектан чагыштырып утыра. Тик нәрсә бу? Хатын аптырашта калды. Чекта исемлеккә кертелмәгән ниндидер өч катлы бисквит бар иде. Бер данә. 550 сум. "Тә-ә-әк", – дип куйды ул. Элек, мәктәптә укыткан чагында, тәртипсезләнә башлаган теләсә кайсы сыйныф шым була иде. Ә инде Әсма Галиевна тактага кемне чакырырга икән, дип, журнал буйлап күзләрен йөгертә башласа, хәтта отличниклар да парта астына кереп качардай булалар иде. Башында уйлар бөтерелә башлады. Торт? Кемгә? Шундый бәягә? Нишләп өйгә алып кайтмаган һәм кая яшергән? Нигә кайту белән гаражга чыгып йөгерде? Менә бит ничек килеп чыга, дип уйлады ул ярсып. Менә сиңа илле еллык тугрылык... Нишләргә инде хәзер? Берни аңлатмыйча куып чыгарыргамы? Алтмыш яшьлек күрше хатыны шатланыр иде. Ни дисәң дә, миннән ун яшькә яшьрәк бит. Сөйләшмичә генә күзәтергәме? Ә аннан соң бәреп үтерергәме? Ире утыз минут өйдә булмаган арада ул аны үтереп тә, терелтеп тә өлгерде, менә бәрәңге күтәреп, гараждан ул үзе кайтып керде.

– Нәрсә, бухгалтер, сдачаны тикшердеңме? – дип сорады ул елмаеп. Беләсеңме, күрше пекарняда нәрсә уйлап чыгарганнар. Алар икенче ишектән көнкүреш химиясе белән сәүдә итәләр, ә тикшерүчеләр бәйләнмәсен өчен, чекка аны торт-мазар итеп төшерәләр. Мин менә 550 сумлык кер юу порошогы алдым...

Виктор ФЁДОРОВ







•••

Бер ир чибәр генә ханым белән танышкач, үзе турында сөйли башлый:

– Мин, әлбәттә, миллионер түгел, тик шулай да...

– Шулай да, – дип бүлдерә аны ханым, – икенче килгәндә миллионер дустыңны ияртеп килергә онытма!

Игорь КИЙКО



Николай ВОРОНЦОВ





СӘНГАТЬ ШУКЛЫГЫ

Екатеринбургта Ельцин Үзәге сакчысы өстеннән суд дәвам итә. Узган елның декабрендә картиналар күргәзмәсен саклаган Александр Васильев, 1934 елда язылган Анна Липовскаяның «Өч фигура» картинасына күзләр ясаган. Третьяков галереясыннан алынган әсәр 75 млн. сумга иминиятләштерелгән булган. «Соавтор» үзенең күзләр ясау теләген ниндидер балалар соравы буенча эшләве белән аңлаткан.

ДЕПУТАТ БОМБАСЫ

Карелиядән килгән депутат Михаил Баев Санкт-Петербургтан Самарага оча торган авиарейска соңга калган. Самолетны тоткарлау өчен, халык ышанычлысы борттагы бомба турында хәбәр итүдән яхшырак нәрсә уйлап тапмаган. Шартлаткыч эзләгәндә ул тыныч кына үз урынын алачак һәм хокук саклау органнарына берәр ничек аңлатылачак дигән карарга килгән. Тик булып чыкмаган...

АУ

Красноярск өлкәсенең Ачинск шәһәрендәге суд приставы 28 яшьлек алимент түләмәүче ананы гадәти булмаган ысул белән эзләп тапкан. Хатын үз балаларына 200 мең сумнан артык бурычы була торып, яшеренеп яткан. Шул чакта пристав хәйләкәрлек белән эш иткән – ул социаль челтәрләрдә бурычлы хатын белән «танышкан» һәм аны очрашуга чакырган. Тегесе ризалашкан. Тик пристав букет урынына юлдан язган әнигә башкару кәгазен сузган, ә ресторан урынына бүлеккә барырга тәкъдим иткән.

МӘЧЕ – ПАТРИОТ ТҮГЕЛ

Курганның бер мәктәбендә укучы ата-аналарына мәчеләр һәм супергеройлар сурәтләнгән көндәлекләр сатып алуны тыйганнар. Педагоглар фикеренчә, укучының төп документында бары тик дәүләт символикасы гына булырга тиеш. Төбәк мәгариф департаментында патриотик теләккә бәя бирмәгән, мәктәпләргә көндәлекне сайлау буенча бернинди тәкъдимнәр дә бирелмәвен белдергәннәр.





• • •

Психиатр үзенә каралырга килгән ханымнан сорый:
– Әйтегез әле, сезнең гаиләдә бөеклек өянәге белән авыручы юкмы?
– Бар. Кайчагында ирем үзен гаилә башлыгы итеп тоя башлый.

Михаил ЛАРИЧЕВ



Виктор ФЁДОРОВ



• • •

Табиб – авыру ханымга:
– Авызыгызны шулкадәр ачмагыз.
– Тамагымны карарга теләдегез бит.
– Эченә кереп карыйм димәдем ләбаса!

Киңәш...

Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

– Сәлам, Сания! Кайларда югалып йөрдең? Күптән күренмисең...

– Авырдым бит. Салкын тигән. Шуңа өйдән чыкмадым.

– Табибларга бардыңмы соң?

– Бардым. Бик күп дарулар яздылар. Барысын да өйгә алып кайткан идем, балалар: "Әни, син нишлисең? Бу даруларның ярамаганнары күп бит", – диделәр. Алай да, эчеп карадым. Килешмәде.

– Ничек килешмәде?

– Берсе эчне җибәрә. Икенчесе – киресенчә. Өченчесеннән баш авырта. Хәлне бетерә. Аннары тән кычыта башлады...

– Инде нишләдең?

– Балаларым бүтән дарулар алып кайтты. "Менә шуларны эч, аларның файдасы булыр", – дип. Дөресен әйткәндә, табиб язган даруларга болай да ышанып бетмим. Белеп бетермиләр алар кемгә нәрсә кирәген.

– Ничек белмәсеннәр инде, табиб бит алар. Шуңа укыганнар.

– Укыганнардыр да... Менә бер мисал китерәм. Элегрәк яңа медицина үзәге ачылганын ишетеп, шунда барырга булдым. Дөрес, яхшы тикшерделәр. Булган-булмаган авыруларны да таптылар. Яхшы дарулар киңәш иттеләр. Рәхмәт яугыры! Аннары аларның язулары белән үзебезнең табибка килдем. Ул озак кына карап утырды да:

– Апа, тагын берәр җиргә барсаң, аннан һәрвакыт миңа кил, яме? – ди. Ә үзе шул арада миңа киңәш ителгән дару исемнәрен үзенә күчереп утыра. Аптыраган идем аңа. Күпмедер вакыттан күрше хатыннары белән ишегалдында сөйләшеп утырабыз. Шунда дарулар турында сүз чыкты. Безнең табиб барысына да миңа киңәш иткән даруларны бирә башлаган икән.

– Әкәмәт!

– Әйе! Күршеләргә күргәнемне сөйләп бирдем. Менә шундый хәлләр...


– Син балалар дару алып кайтты дигән идең. Кайсысы ярдәм итте соң?

– Ул даруларда да шул ук побочный эффект күп булып чыкты.

– Соң, нәрсә белән дәваландың соң? Кайсы даруларны эчеп?

– Берсен дә эчмәдем. Үлән чәйләре кулландым, сөт кайтнатып эчтем. Авыруым үзеннән-үзе үтте дә китте.

Ютәл дә бит шулай: дәвалансаң – ике атнадан, дәваланмасаң унбиш көннән бетә.





Дамир МОРТАЗИН

ШУЛАЙ ИТМИ БУЛМЫЙ...

Ришвәтче турында юмореска яздым. Басырлар дип өмет итмичә, аны шәһәр газетасына җибәрдем. Озакламый мине редакторы чакырды.

– Үткен язылган! Мондый нәрсәләр безгә бик тә кирәк! – дип, кулы белән муенына сызып күрсәтте. – Ләкин юмореска бит... Үзегез беләсез, бик вак һәм җитди жанр түгел... Безнең газетага мәгънәле әсәр кирәк! Эчтәлеген киңәйтебрәк язарга тырышыгыз! – диде.

Мин тырышыбрак, киңәйтебрәк яздым да, аны бастырып та чыгардылар. Тиздән моңа "Әдәби ялкын" журналы игътибар биргәне мәгълүм булды.

– Яшермим, сез аларны шактый яхшы "пешергәнсез"! – дип мактады баш мөхәррирләре, бармагын түшәмгә таба юнәлтеп. – Минем бу әйберегезне үземдә дә күрәсем килә, ләкин, белгәнегезчә, безнең журналыбыз абруйлы. Без повесть югарылыгында фикер йөртәбез. Моңа яңа геройлар өстәп, сюжет юнәлешен катлауландырып, эчтәлеген баету мөһимлеген арттыру кирәк... һәм бернинди дә төрттерү, хихылдау булырга тиеш түгел. Әдәбият – җитдилекне ярата!

Мин повесть язарга тотындым – өстәдем, тирәнәйттем, көлмәдем һәм чеметмәдем. Журналда повесть чыкканнан соң мине театр режиссёры эзләп тапты.

– Сезнең повестьны укыдым. Әйтәсем килә, сез үзегезнең талантыгызны файдалы итеп кулланмыйсыз... – диде.

– Аңламадым? – дидем, аптырап.

– Менә сез повесть язгансыз. Ә повесть нәрсә ул? Укыйсың да, онытыла! Ә пьесада җитдилек һәм озакка калырлык мәгънә. Повестегезне драмага әйләндерегез! Мәхәббәт сюжетын булдырырга онытмагыз... Кирәк нәрсә... бик тә...

Мәхәббәт дигәндә, анысына оста инде мин. Эшләдем. Тиздән хәзерге тормыш белән сугарылган драма әсәре сәхнәләргә менде. Икенче көн иртәсендәге телефон шалтыравы "Три Бэ" телекомпаниясеннән иде.

– Без криминаль телесериягә материал эзлибез. Сезнең пьесаның эчтәлеге сценарийга бик яхшы ята, ләкин шуңа бер-ике үтереш эпизоды, көчләү күренеше кертсәк, бигрәк тә яхшы булыр иде. Һәм дә берәр маньяк, погонлы убырлылар, закондагы бурлар... Тагын шундыйрак нәрсәләр...

– Ә юмор мәсьәләсен өстәсәк ничегрәк? – дип сорап куйдым мин, күптән түгел генә язган юморескамны искә төшереп.

– Аллам сакласын! – диган кире фикер яңгырады телефонның теге башыннан. – Безгә хәзер мәзәк белән шөгыльләнү кирәкми – абруй, дәрәҗәне саклау әһәмиятлерәк...

Аңлашыла да кебек... Яңа сценарий язарга утырдым. Ләкин башымда элеккеге юморескам кайныи. Эзләп таптым да, берничә җөмләсен үзгәртеп, электронка аша журналларына җибәрдем. Җавап тиз килде: "Игътибарыгыз өчен рәхмәт... Ләкин кызганыч... Үзегез беләсез... Хәер, "Үткәннәргә карыйк каерылып" сәхифәсенә бирергә җай табып була..."

– Чукынып китегез! – дидем дә, – Бүген безнең өчен сәнгатьтә әһәмиятлесе – криминаль телесериал! – дип язып куйдым.

Һәм әлеге дә баягы пьесама киллерлар, җыен бозык җаннар, закондагы погонлы хәшәрәтләр тутырып, канәгать калдым.

Алмаз ХӘМЗИН

КӘКРЕ КАЕН

Үткәндә-киткәндә, тәрәзәдән тышка карганда гел искә төшә ул миңа. 43 яшем тулып, гомер буе тулай торакларда яшәп, сукбай хәлендә кунар урын тапмаган чакларда, институтларда укып йөргәндә, өйләнеп, гаилә корып, балалар тугач килде бу бәхет миңа – фатирлы булу. Ниһаять, ишегемне бикләп чыгардай ачкычым бар иде кесәмдә. Мин аның төбенә тузан суырткычымның тузанын түгә идем. Ник дисәгез, ул сазлык киптерергә җаелеп, күп катлы йортлар салынган комлыкта барлыкка килгән каен үсентесе иде. Ичмасам, төбендә кара туфраклы җир барлыкка килер дип уйладым үземчә. Кая барсам да, пакетка тутырып, кара җир дә ташыйм шунда. Нигә шуны кирталәп куймадым икән?.. Таптап та киткәлиләр иде бит... Каерысы да чәйнәлә кайчакта – минем кебек кызганучылар да бар барын... Машиналы кешеләр дә күбәйгәч, урын тарайды үзенә. Күздән дә югалгалый, аралап табам тагын – исән икән. Кышын кар күмеп китә. Язын исән калып чыгуына өмет юк. Карыйсың, тагын калка: бөрешеп беткән, барлы-юклы ботаклары да сынган. Бер метрлы иде бит – җитмеш сантиметрга калган. Әй, каенкай, быел хәлгә килә алмассың инде, дим. Боегып, саубуллашып китеп барам. Байтак вакыт үтте, өйдә тузан суыртырга да вакыт җитми. Мәшәкать бетәмени бу дөньяда?.. Эштә тыгызлык, балалар – берсе мәктәптә, икесе детсадта – алып кайтырга, илтеп куярга; концертлар: кич китәсең, иртән кайтасың, йә атналар буе гастрольләр. Шулай итми булмый – тормышның очын очка ялгарга кирәк. Телевизорда гел "алга барабыз!" диләр. Ә мин дөнья куам – үземчә яшим. Иҗат итәм, дан казанам, янәмәсе... Илдә "перестройка". "Һәр кешегә – аерым фатир!" – дигән иделәр бит. Булыр микән инде ул? Коммунизм төзүне ташлаганнар икән. Минем үз эшем. Халыкка рухи тазалык бирү! Шул яктан игелек кылу – әйбәт ният бит! Көн-төн чабам. Күпләр миңа иярә! Шәрәфи, Шамкай, Хәлим Җәләйләр, Рәшит Сабировлар! Әйе, зыялы юмор-сатира кирәк кешеләргә! Безнең максат шул булырга тиеш! Баксаң, шул арада илнең идеологиясе беткән икән бит... Ә без, ертылып, халкыбызны уйлап йөрибез – кирәк түгел икәнбез лә... – мәхлуклар...


Байтак вакытлар үткән – дөньялар үзгәргән, безгә дә 30–40 яшь өстәлгән. Заманында, Кремль күренеп торачак дип сатылган йортлар, күбрәк катлы йортлар эчендә күмелеп калган. Тирә-юньне ямьләндереп җаелеп яткан матур күлләр югалган. Безнең яндагысына да ике кешенең гомерен йомып, су төбенә алып, хәзер ком җаелеп юл салынган. Ә каен, әлеге дә баягы каен, кәкрәеп кенә булса да үсеп, ботакларын бишенче катка хәтле үрләтеп, һаман күккә омтыла...

Мин аңа карап, үземнең үтеп бара торган гомеремне уйлыйм. Икебез нәкъ бертөсле икәнбез бит...



– Димәк, әбине васыять кәгазе белән бергә ашадың?!

Светлана ФӘТТАХОВА, 1989



Вячеслав БИБИШЕВ, 1998

Игорь КИЙКО



• • •

– Кадерлем, мин балалар күтәргә әзер.

– Ә мин – юк!

– Берни эшләп булмый. Җәй үтте. Аларны авылдан алып килергә кирәк.

• • •

Оныгы – бабасына:

– Бабай, 10 мең биреп тор әле миңа пенсияңнән. Мин сиңа үземнекеннән кайтарырмын.

• • •

Кибеттә.

– Миңа өч шешә аракы.

– Паспортыгызны бирегезче.

– Мин кредитка алмыйм, минем бөтен акчам үзем белән.

• • •

Элек салым инспекциясенә йөрер өчен иске киемнәремне саклый идем. Ә хәзер – теш табибына бару өчен тотам.

• • •

– Ярты гомеремне мин утырып уздырдым.

– Зонадамы?

– Юк, компьютер каршында.

• • •

Шеф үзенең урынбасарына мөрәҗәгать итә:

– Сез минем фирмамда инде 10 елдан артык эшлисез һәм беркайчан да хезмәт хакын арттыру турында сүз кузгатмадыгыз. Сез хәзер нинди яшерен эшләр майтарасыз?

• • •

– Мине кулга алыгыз! – дип кычкыра бер ир полицейскийга. – Мин хатынымның башына кәстрүл белән бәрдем!..

– Ул каты җәрәхәтләндеме?

– Юк, ул хәзер минем арттан куып килә!

• • •

– Берничек тә прессны ныгыта алмыйм.

– Нигә?

– Уңайлы вакыт таба алмыйм: йә ашау вакытына туры килә, йә әле генә ашаган чак.

• • •

Мошенниклардан хат килә. Язганнар: һәр ай саен безгә акча бир, ә без аны 65 яшең җиткәч кире кайтара башлыйбыз. Моннан да мәгънәсез алдауны минем беркайчан очратканым булмады.

• • •

– Улым, "Совет көнкүреш музеена" барасың киләме?

– Әти, бакчабызга бүтән барасым килми!



Александр ШУЛЬПИНОВ



Валентин ДРУЖИНИН





БӨКЕЛЕ ЯШӘЕШ

Кадерле "Чаян"! Акрын йөрсәң – ераккарак барырсың. Безнең бу очракта – билгеләнгән урыннан. Биектаудагы "Ак аллея" торак комплексы төзелеше Наратлы һәм үзәк – Зур Кызыл урамындагы хәрәкәтне тулысынча туктатты. Әле бит андагы йортларда барлык фатирларда кешеләр яшәми дә. Хәзер, Казанга бару өчен сәгатьләр буенча бөкедә утырырга туры килә: башта бистәдә, аннан соң шәһәргә җитәр алдыннан. Күрәсең, Салмачи һәм Салават Күпере тәҗрибәсе берәүгә дә сабак бирмәде. Һаман шул тырмага басабыз түгелме? Мондый хәл килеп чыгасы көн кебек ачык иде бит – юлларның машина сыйдырышлыгын берәү дә исәпләми шул. Төзиләр дә качалар – "бездән соң ник шунда су басып китми", диләрдер...

Биектау бистәсендә яшәүчеләр.

АҢЛАШЫЛМАГАН ЫСУЛ

Хөрмәтле редакция! Һәрберебезгә мәгълүм, ремонт ясау – мәшәкатьле һәм әчпоштыргыч эш. Җитмәсә, кайчагында әле бик тә тончыгышлы исле. Чистай һәм Амирхан урамнары киселешендә башланган ремонт эшләре һаман дәвам итә. Менә шул вакыттан бирле якын-тирәдәге йортларда яшәүчеләр сасы истән иза чигәләр. Чистай урамындагы 82, 72, 74 нче йортларның подвалында сәер исле су тышка чыгып, газоннарга җәелде, тротуарлардан һәм юллардан ага. Тәрәзәләрне ача торган түгел. Урамга чыгып, бераз йөреп керим дисәң – респиратор кирәк.

"Водоканалда" ремонт эшләре график буенча үтәлеп бара, дип аңлаталар. Заманча технология белән, барлык ысуллар кулланылып, диләр. Яңача эшләү алымы, кирәкле гамәлләрне йортлардагы суны туктатмыйча башкарырга мөмкинлек бирә, дип сөендерәләр. Бу "сөендерү" инде ел буена сузылды. Бәлки, искечәрәк эшләү кулайрактыр дигән уй керә күңелгә һәм чыкмый интектерә!..

И. БАРУКИНА

КАЗАН

Александр АЛЁШИН





Валентин ДРУЖИНИН



Шамил ХӘЛИЛУЛЛОВ



Николай ВОРОНЦОВ



Рәшит ЗӘКИЕВкә – 85!



Рәшит Зәкиев исеме, заманында Ленин һәм партия шикелле, "Чаян"нан аерылгысыз булды. Бу гаҗәп түгел, чөнки ул 30 елдан артык бөтен илгә дан тоткан юмор һәм сатира журналын җитәкләде. Җитәкчелек эше белән генә чикләнмичә, Рәшит Кәрипович профессиональ журналист, шагыйрь, хикәяче буларак, үз иҗаты белән дә басмабызны баетып килде. Басынкы, тыныч холыклы кеше – ул илдәге иң катлаулы елларда, дөньяның асты-өскә килгәндә дә журналны саклап кала алды. Безнең күбебез аның тарафыннан эшкә кабул ителгән, ул туплаган команда кешеләре, һәм бүген дә ул күрсәткән юлдан тайпылмаска тырышабыз. Юбилеегыз белән, Рәшит Кәрипович!

* * *

Бу яшьлек елларым, сагынып елларым
Томанга төренеп югала.
Кайтмыйлар кирегә барыбер,
Күңелем, моңайма, моңайма.
Дөньяның әйбәтен, яманын
Сиңа да сынарга язган бит.
Абынсаң, ялгышсаң, тор да син,
Берни дә булмаган сыман ит.
Барасы, ачасы йолдызым
Еракта, еракта нурлана.
Нигә соң шулкадәр ешкынлы,
Ешкынлы шулкадәр нигә соң,
Мин үтә торган бу урманнар?
Чыдармын барсына, барсына,
Язмышым, син кайдан урама,
Авырны, яманны җиңәрмен,
Җиңәрмен авырны, яманны, –
Мин әзер иң кыен юлларга.

60 нчы еллар

МАССАЖ

Хәмәйгә массаж ясыйлар,
Уалар каткан билен.
Аркасына пудра сибеп,
Кул янтыгы белән төеп,
Куалар сырхау җилен.


Йөзтүбән ята Хәммәтдин,
Мактап массажчы кулын.
Шифасына өмет кылып,
Рәхәтеннән онытылып,
Чак ала теге тынын.

Атна түгел, айлап йөрде –
Бил һаман каткан көйгә.
Эш чыкмагач, түзеп-түзеп,
Массажыннан өмет өзеп,
Атлады сырхау өйгә.

Сәбәбен әйткәч беркөнне,
Калды бит Хәмәй өнсез:
Ялагай биле массаждан
Турайммый икән, юньсез...

80 нче еллар

Мидхәт САДЫЙКОВ



"Без өйләнгәч, төн кыскарды".

– Ничек инде? Җәй көне төн болай да кыска була бит. Сез үзегез җиләкләр пешкән чакта тормыш корып җибәрдек, дисез.

– Син уйлаганча түгел шул ул, энекәш, – диде Галим абый.

– Алайса тыңлыйбыз, – дидек без, аңа якынрак килеп.

– Узган гасырның 80 нче елларыннан, Совет заманыннан ук башлыйм инде алайса. 1984 елда мине юллама буенча Казан артындагы бер район газетасына эшкә җибәрделәр. Бер елдан соң баш мөхәррир урынбасары лаеклы ялга китә икән. Мине шушы урынга әзерләргә тиешләр. Әлегә тәрҗемәче-хәбәрче вазыйфасында. Ул чакта иң зур пенсия – "шахтер пенсиясе" саналып килендә. Ул – 120 сум. Стажы, эшләгән акча күләме тиешле биеклеккә җитсә, моңа тагын 12 сум өстәлә икән. Минем "шеф" та шуңа омтыла. Тик айлык хезмәт хакы 300 дән артып китсен өчен, окладтан тыш, тагын 130 сум гонорар эшләргә тиеш булып чыга. Моңа ирешү өчен көн-төн эшләргә, айга унике сан чыккан район газетасының һәрберсенә икешәр-өчәр саллы гына язмалар урнаштырып барырга кирәк. Редакторат тарафыннан кайбер нәрсәләргә "күз йомган" очрак та булмый калмагандыр инде. Монда бернинди криминал юк үзе. Бүген – ул, иртәгә – син, дигән күзлектән чыгып, алдан килешенеп эшләнә торган гамәл бу. Дөрес, башка хезмәткәрләргә бер ел буе бераз кысылыбрак яшәргә туры килә инде анысы. Ярар, хуш. Шул алым белән әүвәл Гамир абыйны, икенче елны Петр дәдәйне лаеклы ялга озаттык. Абзыйлар бик канәгать булып, безгә дә шундый бәхетле көннәрне күрергә, иң зур пенсияләр белән чыгарга язсын, дип, күз яшьләре белән җылы теләкләрен ирештерделәр. Еллар үтте. Район газетасыннан китеп, икенче җирдә эшләсәк тә, әлеге матур уйлар бер онытылып, бер искә төшеп дигәндәй, күңелне һаман бимазалап торды. Баксаң, республика газеталарында һәм мин эшли торган журналда да бу традиция дәвам итә икән. Акрын гына минем дә пенсиягә чыгар вакытым якынлашты. Тагын биш-алты елдан мине дә куккә чөячәкләр, акчага күмәчәкләр, "пирамида"ның түбәсендә син, син, син, диячәкләр! Әнә шундый уйлар белән сөенә-сөенә эшләп йөргән көннәрнең берсендә "Татмедиа" оеша дигән хәбәр килде... һәм оешты... һәм барлык редакцияләрне үз канаты астына алып, матур гына эшләп тә китте. Без ничек эшләгән булсак, шулай эшләп йөрибез. Хисапчылар гына берләште. Алар каядыр өстәге катта утыралар дип ишеттем. Бер... ике ел үтте. Мәнә без дә 58 яшьне тутырдык, Аллага шөкер! Аннары... күп калмый инде. Теге "шахтер пенсиясе" күңелне бимазалап тора дигән идем бит әле. Туктале, мин әйтәм, белешә торыйм, дип, бухгалтериягә кагылып чыгарга булдым. Ишекне ачып бүлмәләренә кергән идем, компьютерларыннан күтәрелеп, миңа дүрт кыз карады. Әйтерсең дүрт игезәк. Сайлап җыйсаң да болай ук булмас. Алпан-тилпән атлап йөрүче хисапчыларны гына күрергә күнеккән минем күз әлеге манзараны ялгыш күрсәтә дисәм... Мин нәрсәгә кергәнемне искә төшерергә омтылып басып торганда: "Сез кайсы редакциядән?" дигән ягымлы тавыш айнытып җибәрде.

– Алайса сез – миңа.

Мин тәрәзә янында утыручы туташ каршына килеп бастым да аның утә сыек зәңгәр күзләренә бактым.

– Әйе, тыңлыйм, абый.

– Мин...миңа...миңа уртача хезмәт хакы турында белешмә кирәк иде. "По месту требования". Интуициянe әйт син, хәтерне... Балалар бәләкәй чакта җанга тигән "җөмләне" моментында искә төшерүен кара.

Йөрәгемне "учыма тотып" дигәндәй, бүлмәдән чыктым да стенага сөялдем. Тиз генә китеп барырга аяклар атламый идеме шунда. Бераздан ишек ачылды, аннан теге сыек зәңгәр күзле кыз чыгып, бер мизгел миңа карап торды да:

– Абый, сез авырмыйсызмы? – дип сорады.

– Юк, юк, димәкче идем, тел әйләнмәде.

Баш кагып кына аңлатырга туры килде.

Кичке якта, вәгъдә ителгәнчә, сыек зәңгәр күз миңа уртача хезмәт хакы турындагы белешмәне төшереп бирде. Анда айлык хезмәт хакы 25 мең дип язылган иде. Бу суммадан күпме пенсия акчасы чыгасын уйларга батырчылыгым җитмәде...

Аннары айлар, берәр ел үттеме шунда, мөһим түгел, пенсиягә чыгу яшен биш елга арттырып куйдылар. Минем "хыялый баш" монысын ук көтмәгән иде. Бик озак аңгыраеп йөредем. "Без өйләнгәч төн кыскарды" дигән әйтем-мәкальнең мәгънәсен мин шулай итеп аңлатыр идем. Ярар инде, дим, килешми ни эшлисең, ил белән бит, дим. Ашханәгә төшкәч, ерактан гына теге сыек зәңгәр күзләргә карап-карап куям. Тирәндә шундыйлар эшләгәндә ялга китәсе киләмени ул... Их, берни белмисез сез, егетләр, дип, Гамил абый хикәясен тәмамлады. Аннары: " Сезнең эш беткән булса, минеке башлана гына әле. Мәкалә язасы бар", – дип, өенә кереп китте. Ә без, яшьләр, мәдәният йортына юнәлдек.



САТИРА һәм
ЮМОР ЖУРНАЛЫ
1923 елдан чыга.

№ 10 (1923) октябрь 2022

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе
«ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре,
Академическая урамы, 2


Матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләре агентлыгы
ярдәмендә оештырылган.
Журнал
Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.
«Журналга «Почта России» каталогы,
йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша
язына алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).
Редакция материалларны авторларның
ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү
хокукына ия.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 01.10.2022 ел.
Тираж – 2520 Заказ О-2838

Редакциянең адресы: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.
Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+

Уйна да, уйла да!



Ринат АБЗАЛОВ төзеде



1. Ни өчен эштәге соңгы сәгатьләр кайберәүләр өчен иң авыры?

2. Мәзәкләрне күп белү ни өчен начар?

3. Нигә хатын-кызлар коллективында эшләве авыр санала?

4. Ял итү эштән нәрсә белән аерыла?

5. Украина борщын, французларның суган шулпасын һәм алманнарның сосискаларын нәрсәсез әзерләп булмый?

6. Әгәр эшегез – яшәвегезнең мәгънәсе икән – бу нәрсәне аңлата?

7. Өйләнешүнең хәвефлеге нәрсәдә?

ҖАВАПЛАР

1. Чөнки сезнең инде бернәрсә дә эшлисез килми, ә эшләргә кирәк. Чөнки алдагы сигез сәгатьләрне чәй эчеп һәм социаль челтәрләрдә уздырдыгыз. 2. Кирәк чагында – искә төшми, ә башкалар сөйләгәндә – кызык түгел. 3. Әгәр бәйләнә башласаң, сиңа бабник дип әйтәчәкләр. Бәйләнмәсәң – гей. 4. Интернетка кайсы компьютердан керүегез белән. 5. Рәсәй газыннан башка. 6. Димәк, сезнең эшегез бик күңелле яисә тормышыгыз үтә яман. 7. Гүзәллеккә өйләнәсең, ә холкы белән яшәргә туры килә.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 9 нчы санында басылган чаянвордның тикшерү сүзе – **«КЫР КАЗЛАРЫ АРТЫННАН»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Г. БАҺАВЕТДИНОВ (Чаллы),
Г. ИДРИСОВА (Биектау),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).


Җиңүчебез – Чаллыдан **Гали БАҺАВЕТДИНОВ!**



Валерий Тарасенкодан КӨЗГЕ СӘЛАМ











4612750670080